КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2024 ел, 18 июль

г.Казань

№ 577

2024 елда Иннополис шәһәре территориясендә җылылык белән тәэмин итү хезмәтләрен күрсәтүче оешмаларга субсидия бирү чыгымнарын финанс белән тәэмин итү, әлеге эшчәнлекне гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарның бер өлешен финанс белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районына Татарстан Республикасы бюджетыннан финанс белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды бюджет ассигнованиеләре булган башка бюджетара трансфертларны бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2024 елда Иннополис шәһәре территориясендә җылылык белән тәэмин итү хезмәтләрен күрсәтүче оешмаларга субсидия бирү чыгымнарын финанс белән тәэмин итү, әлеге эшчәнлекне гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарның бер өлешен финанс белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районына Татарстан Республикасы бюджетыннан финанс белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды бюджет ассигнованиеләре булган башка бюджетара трансфертларны бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 18 июль, 577 нче
карары белән расланды

2024 елда Иннополис шәһәре территориясендә җылылык белән тәэмин итү хезмәтләрен күрсәтүче оешмаларга субсидия бирү чыгымнарын финанс белән тәэмин итү, әлеге эшчәнлекне гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарның бер өлешен финанс белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районына Татарстан Республикасы бюджетыннан финанс белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды бюджет ассигнованиеләре булган башка бюджетара трансфертларны бирү тәртибе

I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Тәртип 2024 елда Иннополис шәһәре территориясендә җылылык белән тәэмин итү хезмәтләрен күрсәтүче оешмаларга субсидия бирү чыгымнарын финанс белән тәэмин итү, әлеге эшчәнлекне гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарның бер өлешен финанс белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районына Татарстан Республикасы бюджетыннан финанс белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды бюджет ассигнованиеләре булган башка бюджетара трансфертларны (алга таба шул ук эзлеклелектә – муниципаль район, башка бюджетара трансфертлар) бирү механизмын, максатларын һәм шартларын билгели.

2. Әлеге Тәртип нигезендә бирелә торган бюджет акчасы белән баш эш итүче – Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы (алга таба – Министрлык).

3. Башка бюджетара трансфертлар 2024 елда әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен билгеләнгән тәртиптә Министрлыкка җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм бюджет ассигнованиеләре чикләрендә бирелә.

4. Әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен башка бюджетара трансфертлар бирүгә бүлеп бирелә торган бюджет ассигнованиеләре күләме Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты акты белән билгеләнә.

5. Муниципаль район бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары:

Иннополис шәһәре территориясендә җылылык белән тәэмин итү хезмәте күрсәтүче оешмаларга әлеге эшчәнлекне гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарның бер өлешен финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) субсидияләр бирү тәртибен билгели торган муниципаль районның хокукый акты булу;

муниципаль берәмлек бюджетында (муниципаль берәмлек бюджетының җыелма бюджет исемлегендә) муниципаль берәмлекнең финанслашу максатларында башка бюджетара трансфертлар бирелә торган чыгым йөкләмәләрен үтәү өчен бюджет ассигнованиеләре булу;

әлеге Тәртипнең 10 пункты нигезендә Министрлык һәм муниципаль район арасында башка бюджетара трансфертлар бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзү.

6. Башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсе – Иннополис шәһәренең кулланучыларына җылылык белән тәэмин итү буенча коммуналь хезмәтләр күрсәтүнең ышанычлылыгы һәм сыйфаты.

Субсидияләр бирү нәтиҗәсенә ирешү өчен кирәкле күрсәткеч – бер ел эчендә ягулык ихтыяҗлары өчен, коммуналь ресурсның (коммуналь хезмәтнең) сыйфатына карата норматив таләпләр бозылмыйча, коммуналь ресурс (коммуналь хезмәт) күрсәтелә торган көннәр саны.

7. Башка бюджетара трансфертлар алу өчен муниципаль район Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

әлеге Тәртипнең кушымтасында бирелгән форма буенча башка бюджетара трансфертлар бирүгә заявка (алга таба – заявка);

заявкага кул куйган затның вәкаләтләрен раслый торган документ;

Иннополис шәһәре территориясендә җылылык белән тәэмин итү хезмәте күрсәтүче оешмаларга әлеге эшчәнлекне гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарның бер өлешен финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) субсидияләр бирү тәртибен билгели торган муниципаль районның расланган хокукый акты күчермәсе;

муниципаль районның 2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына муниципаль район бюджеты (муниципаль район бюджетының җыелма бюджет исемлеге) турындагы карарыннан муниципаль район бюджетында (муниципаль район бюджетының җыелма бюджет исемлегендә) Иннополис шәһәре территориясендә җылылык белән тәэмин итү хезмәтләрен күрсәтүче оешмаларга әлеге эшчәнлекне гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарның бер өлешен финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) муниципаль районның чыгым йөкләмәләрен үтәүгә бюджет ассигнованиеләре булуын раслый торган өземтә.

8. Министрлык:

заявканы кергән көнендә теркәүгә ала;

заявка теркәлгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә бу Тәртипнең 7 пунктында күрсәтелгән документларны карап тикшерә һәм башка бюджетара трансфертлар бирү турында яки башка бюджетара трансфертлар бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

9. Башка бюджетара трансфертлар бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

әлеге Тәртипнең 7 пунктында күрсәтелгән документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

муниципаль район тарафыннан әлеге Тәртипнең 5 пунктында каралган башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары үтәлмәү.

Муниципаль район әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләрне үтәү шарты белән башка бюджетара трансфертлар бирүдән баш тарту турында хәбәрнамә алган көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә документларны кабат тапшырырга хокуклы.

10. Башка бюджетара трансфертлар башка бюджетара трансфертлар бирү турында карар кабул ителгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн

эчендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бертип форма буенча Министрлык һәм муниципаль район арасында төзелә торган килешү нигезендә бирелә.

11. Килешүдә түбәндәгеләр карала:

башка бюджетара трансфертларның максатчан билгеләнеше;

бирелә торган башка бюджетара трансфертлар күләме;

башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсенең күрсәткече;

башка бюджетара трансфертларны күчерү тәртибе һәм сроклары;

финанслашу максатларында башка бюджетара трансферт бирелә торган чыгымнар турында һәм аларга ирешү максатларында кабул ителгән башка бюджетара трансферт һәм йөкләмәләр бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисапларны тапшыру формасы һәм сроклары;

башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсенең билгеләнгән күрсәткеченә ирешмәү нәтиҗәләре;

Министрлык белән дәүләт финанс контроле органнарының муниципаль район тарафыннан килешүдә каралган башка бюджетара трансфертлардан файдалану йөкләмәләренең үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибе.

12. Башка бюджетара трансфертлар Министрлык тарафыннан килешү төзелгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә муниципаль районның финанс органына ачылган муниципаль район бюджетының бердәм счетына күчерелә.

13. Муниципаль район квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган бишенче эш көненнән дә соңга калмыйча, Министрлыкка Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан килешүнең бертип формасына теркәлә торган формалар буенча финанслашу максатларында башка бюджетара трансфертлар бирелә торган чыгымнар турында хисап һәм башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешү һәм аңа ирешү максатларында кабул ителгән йөкләмәләр турында хисап тапшыра.

14. Башка бюджетара трансфертлардан файдалануның нәтиҗәлелеген бәяләү Министрлык тарафыннан килешүдә билгеләнгән башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсенең күрсәткечләрен 2024 ел йомгаклары буенча фактта ирешелгән башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсенең күрсәткечләре белән чагыштырып карау юлы белән гамәлгә ашырыла.

15. Муниципаль район әлеге Тәртипнең 13 пункты нигезендә тапшырыла торган хисап мәгълүматларының дөрес булмавы һәм башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдаланылмавы өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап бирә.

16. Әгәр башка бюджетара трансферт бирелгән елның 31 декабренә карата муниципаль район тарафыннан килешүдә билгеләнгән башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсенә ирешелмәгән булса, башка бюджетара трансфертлар муниципаль район бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына башка бюджетара трансферт бирелгән елдан соң килә торган елның 1 мартына кадәр кире кайтарылырга тиеш.

17. 2025 елның 1 гыйнварына карата файдаланылмаган башка бюджетара трансфертлар акчасы 2025 елның беренче 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджеты керемен кире кайтарылырга тиеш.

Башка бюджетара трансфертларның файдаланылмый калган өлеше Татарстан Республикасы бюджеты кеременә күчерелмәгән очракта, әлеге акча, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләрне үтәп, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә түләтелергә тиеш.

Хисап финанс елында файдаланылмаган башка бюджетара трансфертларның калган өлешен әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга тотуга ихтыяҗ булган очракта, муниципаль район Министрлыкка 2025 елның беренче 15 эш көненнән дә соңга калмыйча шундый ихтыяҗны нигезләп мәгълүмат бирә.

Министрлык, муниципаль районнан әлеге пунктның өченче абзацында күрсәтелгән мәгълүматны алган көннән алып 30 календарь көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештереп, агымдагы финанс елында хисап финанс елында файдаланылмаган башка бюджетара трансфертларның калган өлешен тотуга ихтыяҗ булу яисә булмау турында карар кабул итә.

Министрлык агымдагы финанс елында хисап финанс елында файдаланылмаган башка бюджетара трансфертларның калган өлешен тотуга ихтыяҗ булу турында карар кабул иткән очракта, Министрлык һәм муниципаль район арасында мондый карар кабул ителгән көннән алып өч эш көне эчендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән килешүнең бертип формасына теркәлә торган форма буенча килешүгә өстәмә килешү төзелә.

18. Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары бу Тәртип һәм килешү белән билгеләнгән башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыра.

19. Башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдаланылмаган һәм (яки) муниципаль район тарафыннан аларны бирү шартлары бозылган, шул исәптән акча әлеге Тәртипнең 17 пункты нигезендә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылмаган очракта, аңа карата Россия Федерациясенең бюджет законнарында каралган мәҗбүр итү чаралары кулланыла.

Башка бюджетара трансферлардан максатчан файдаланмау Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган акча суммасын Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә бәхәссез түләтүгә китерә.

20. Башка бюджетара трансфертларның максатчан кулланылышын контрольдә тоту Министрлык тарафыннан законнар нигезендә башкарыла.

2024 елда Иннополис шәһәре территориясендә җылылык белән тәэмин итү хезмәтләрен күрсәтүче оешмаларга субсидия бирү чыгымнарын финанс белән тәэмин итү, әлеге эшчәнлекне гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарның бер өлешен финанс белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районына Татарстан Республикасы бюджетыннан финанс белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды бюджет ассигнованиеләре булган башка бюджетара трансфертларны бирү тәртибенә кушымта

Форма

Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры

______________________________________
______________________________ ка (га)
(муниципаль район җитәкчесенең (аның вазыйфаларын

______________________________________
башкаручы затның) фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда) (тулысынча)

2024 елда Иннополис шәһәре территориясендә җылылык белән тәэмин итү хезмәтләрен күрсәтүче оешмаларга субсидия бирү чыгымнарын финанс белән тәэмин итү, әлеге эшчәнлекне гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарның бер өлешен финанс белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районына Татарстан Республикасы бюджетыннан финанс белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды бюджет ассигнованиеләре булган башка бюджетара трансфертларны бирүгә заявка

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2024 елда Иннополис шәһәре территориясендә җылылык белән тәэмин итү хезмәтләрен күрсәтүче оешмаларга субсидия бирү чыгымнарын финанс белән тәэмин итү, әлеге эшчәнлекне гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарның бер өлешен финанс белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районына Татарстан Республикасы бюджетыннан финанс белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды бюджет ассигнованиеләре булган башка бюджетара трансфертларны бирү тәртибен раслау турында» 2024 ел, 18 июль, 577 нче карары белән расланган 2024 елда Иннополис шәһәре территориясендә җылылык белән тәэмин итү хезмәтләрен күрсәтүче оешмаларга субсидия бирү чыгымнарын финанс белән тәэмин итү, әлеге эшчәнлекне гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарның бер өлешен финанс белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районына Татарстан Республикасы бюджетыннан финанс белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды бюджет ассигнованиеләре

булган башка бюджетара трансфертларны бирү тәртибе нигезендә

______________________________________________________________________________

(муниципаль район исеме)

______________________________________________________________________________

(чара исеме, башка бюджетара трансферт бирү максаты)

______________________________________________________________________________

___________________(___________________________________) сум ___ тиен күләмендә

(сумма цифрлар белән) (сумманы тутырып язу)

башка бюджетара трансферт бирүегезне сорыйм.

Әлеге заявкада бирелгән белешмәнең дөреслеген һәм тулылыгын раслыйм.

Дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар биргән өчен җаваплылык турында кисәтелдем.

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча бюджетара башка трансфертлар алу өчен дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшырылган, башка бюджетара трансферт биргәндә билгеләнгән шартлар, максатлар һәм тәртип, башка бюджетара трансферттан файдалану бозылган очракта, бирелгән башка бюджетара трансфертны Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарырга тиеш турында беләм.

Җитәкче

(аның вазыйфаларын башкаручы зат) _______________ / _____________________________________________/

(имзасы) (Ф.Ис.Ат.ис. (соңгысы – булганда))

М.У.

Дата: 20___ ел, «____» ______